Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Осинники авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

**20 мая 2022 ел** **№ 48**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында массакүләм мәгълүмат чараларына хәбәр итү һәм «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүматтелекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибен раслау турындагы» 2017 елның 6 сентябрендәге 56 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында.

«Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 4 өлеше , Россия Федерациясе Президентының «Аерым категория затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне федераль дәүләт органнарының, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарының һәм оешмаларының рәсми сайтларында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны Бөтенроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе» 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы Указының 2 пункты, Кама Тамагы районы прокурорының 2022 елның 29 мартындагы 02-08-02 номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Кама Тамагы муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм

мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турында Нигезләмә хакында» 2015 елның 22 маендагы 122 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында массакүләм мәгълүмат чараларына хәбәр итү һәм «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибен раслау турындагы» 2017 елның 6 сентябрендәге 56 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 3 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Рәсми сайтларда гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына урнаштырыла һәм вазыйфаларын биләүче затларның (хезмәткәрләрнең) керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бастырып чыгару өчен бирелә»;

2.2. 3 пунктның а), б), в) абзацларында, “вазыйфаи затка” сүзләрен “хезмәткәргә (эшчегә)” сүзләренә алмаштырырга;

2.3. 3 пунктта г)абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган (алыш-биреш суммасы) хисап чорына кадәрге соңгы өч елда хезмәткәрнең (эшченең) һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып киткән булса, акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр»

2.4. 4 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Рәсми сайтларда урнаштырылган һәм гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр

турында белешмәләрне бастырып чыгару өчен бирелгән массакүләм мәгълүмат чараларында түбәндәгеләрне күрсәтү тыела:

2.5. 4 пункттагы а), б), в), г) абзацларында, «вазыйфаи зат» сүзләрен «хезмәткәр (эшче)» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Осинники авыл җирлеге башлыгы
Кама Тамагы муниципаль районы
Татарстан Республикасы, Дәүләт Советы
Рәисе Осинники авыл җирлеге башлыгы
Кама Тамагы муниципаль районы
Татарстан Республикасы А. Х. Сәгъдиев